| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТА РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

24.04.2026 №60-п

Буа муниципаль районында гражданнар оборонасын алып бару һәм алып баруга әзерлек тәртибе» 2009 елның 4 февралендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон ( 23.07.2025 редакциясендә), «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары (19.01.2026 редакциясендә), «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы ( 26.07.2024 ред) һәм «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы белән (17.12.2021 редакциясендә) карар бирәм:

1. «Буа муниципаль районында гражданнар оборонасын алып бару һәм алып баруга әзерлек тәртибе» 2009 елның 4 февралендәге 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15.2 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән муниципаль һәм локаль халыкка хәбәр итү системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту;»

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы башлыгы Р.Р.Камартдинов